РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

2020 елның 7 мае Кукмара шәһәре № 281

«Кукмара муниципаль районының 2020 елга һәм 2021, 2022 елларның план чорына бюджеты турында» Кукмара муниципаль район Советының 2019 елның 13 декабрендәге 258 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына Кукмара муниципаль районы бюджетына Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тәкъдим иткән үзгәрешләрне карап, Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

«Кукмара муниципаль районының 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджеты турында» Кукмара муниципаль районы Советының 2019 елның 13 декабрендәге 258 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2020 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Кукмара муниципаль районы бюджетының фаразлана торган гомуми керем күләме 1 276 058 585,16 сум;

2) Кукмара муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1 289 710 869,43 сум;

3) Кукмара муниципаль районы бюджеты дефициты (профициты) 13 652 284,27 сум.

2. Түбәндәге эчтәлекле $17^1$ статьяны өстәргә:

«$17^1$. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Бердәм реестрына кертелгән һәм Кукмара муниципаль районының муниципаль милкен арендалаучы (шул исәптән җир кишәрлекләрен) һәм дәүләт милке чикләнмәгән һәм аларны бирү Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән җир кишәрлекләрен арендалаучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мондый мөлкәтне арендалау

шартнамәләре буенча аренда түләүләрен 2020 елның апрель – июнь айларында кичектереп тору яки мондый мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүдән 2020 елның апрель – июнь айларында азат итү бирелә.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары булып торучы реклама конструкцияләре хуҗаларына реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен 2020 елның апрель – июнь айларында исәпләнгән түләүләр кичектерелә.

Аренда түләүләрен һәм реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүне кичектереп тору шартлары һәм сроклары, аренда түләүләрен түләүдән азат итү шартлары, аренда түләүләрен түләүдән азат итү хокукы булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары төрләре Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының аерым карары нигезендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль милкен (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалаучылар һәм дәүләт милке чикләнмәгән һәм аларны бирү Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән җир кишәрлекләрен арендалаучы һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләренең хуҗалары тарафыннан 2020 елның 1 апреленнән 30 июненә кадәр Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының аерым карарында каралган тәртиптә һәм шартларда аренда түләүләре һәм реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә түләүләр кертү буенча бурычларын үтәмәгәндә (тиешенчә үтәмәгәндә), җаваплылык чаралары кулланылмый.».

3. Кукмара муниципаль районының 2021 елга һәм 2022 елга бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Кукмара муниципаль районы бюджетының фаразлана торган гомуми керем күләме 2021 елга 1 283 898 971,77 сум һәм 2022 елга 1 296 490 131,78 сум күләмендә;

2) Кукмара муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2021 елга 1 283 898 971,77 сум һәм 2022 елга 1 296 490 131,78 сум;

3) Кукмара муниципаль районының бюджет дефициты (профициты) 2021 елга 0 сум, 2022 елга 0 сум.

4. Кукмара муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын билгеләргә:

2020 елга әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә;

2021 елга һәм 2022 елга әлеге карарның 2 нче кушымта нигезендә.

1) 2020 елга Кукмара муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә үзгәртергә.

2) 2020 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының фаразланган керем күләмен әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә үзгәртергә.

3) 2020 елга Кукмара муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә үзгәртергә.

4) 2020 елга бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне карарның **4 нче кушымтасы** нигезендә үзгәртергә.

5) 2020 елга **Кукмара муниципаль районы** чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарның **5 нче кушымтасы** нигезендә үзгәртергә.

6) 2020 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирлекләр бюджетларыннан алына торган бюджетара трансфертларны әлеге карарның **6 нчы кушымтасы** нигезендә үзгәртергә.

Район Башлыгы Димитриев С. Д.